**Татарстан Республикасы**

**Тукай муниципаль районы**

**"Теләнче-Тамак авыл җирлеге"**

**муниципаль берәмлек Советы**

# КАРАР

"14"сентябрь 2018ел № 34/3

Татарстан Республикасы "Тукай муниципаль районы Теләнче-Тамак авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыеннарын әзерләү тәртибе турында " Нигезләмәне раслау хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1 статьясын, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясын һәм Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районының «Теләнче-Тамак авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 13.1 статьясын гамәлгә ашыру максатларында, Теләнче-Тамак авыл җирлеге Советы ,

**КАРАР КЫЛДЫ:**

1.Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Теләнче-Тамак авыл җирлеге торак пунктларында, кушымта нигезендә, гражданнар җыеннарын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турында " Нигезләмә расларга.

2. Әлеге карар Теләнче-Тамак авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында рәсми басылып чыккан мизгелдән үз көченә керә.

3.Аның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Теләнче-Тамак авыл җирлеге башлыгына йөкләргә.

Муниципаль берәмлек башлыгы,

Совет рәисе Р.Ш. Нәҗметдинов